**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КРАСНОСЕЛЬСКИЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422700, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Биектау тиемер юл станциясе поселогы, Совет урамы, 13

**СОВЕТ КРАСНОСЕЛЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422700, Республика Татарстан, Высокогорский район, п. ж/д ст. Высокая Гора, ул. Советская, 13

тел./факс 8(84365) 2-35-82,e-mail: Ksel.Vsg@tatar.ru

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**
**7 апрель 2023 ел** **№ 67**

**Красносельский авыл җирлеге Советының 2019 елнын 21 октябрендэге 144 нче номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельское авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында**

2007 елның 2 мартындагы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 25-ФЗ номерлы, 2022 елның 5 декабрендәге «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 498-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, шулай ук Биектау районы прокурорының 2023 елның 18 январендәге 02-08-01 номерлы Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Советының 2019 елның 21 октябрендәге 144 нче номерлы карарына протестын карап чыгып, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Красносельский авыл җирлеге Советының 2019 елнын 21 октябрендэге 144 нче номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельское авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә (Советның 2020 елның 26 февралендәге 158 нче номерлы, 2020 елның 20 ноябрндәге 8 нче номерлы, 2021 елның 2 сентябрендәге 30 нчы номерлы карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 нчы маддәнең 1 нче пунктын түбәндәге эчтәлектәге 12 нче пунктчы белән тулыландырырга:

«12) аның чит ил агенты статусын алуы.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Биектау районы, Биектау тимер юл станциясе поселыгы, Совет урамы, 13 нче йорт адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Башкарма комитеты бинасынын махсус мәгълүмат стендында, Биектау муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адресы буенча рәсми сайтында авыл җирлекләре бүлегендә һәм Татарстан Республикасы Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Красносельский авыл җирлеге
Башлыгы урынбасары Р.Р. Никитенко